УДК 374.7

# СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЕЛЛАРЫНДА ТАТАРЛАР АРАСЫНДА УКЫЙ–ЯЗА БЕЛМӘҮЧЕЛЕКНЕ БЕТЕРҮНЕҢ КАЙБЕР МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ (ТАССР МИСАЛЫНДА)

***Л.Р. Мортазина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*lyalyamur@mail.ru*

Мәкаләдә Совет властеның беренче елларында илдә җәелдерелгән иң күләмле кампанияләрнең берсе булган ликбез кампаниясен татарлар арасында үткәрүнең үзенчәлекләре яктыртыла. Татарстан шартларында ликбез эшен тормышка ашыруның юллары, формалары, ликбез мәктәпләрендә кулланылган дәреслек һәм методик әсбаплар, татар вакытлы матбугатында укый–яза белмәүчелек мәсьәләләренең яктыртылышы тасвирлана.

**Төп төшенчәләр:** ликбез, укый–яза белмәүчелек, укырга–язарга өйрәтү, ликпункт, ликвидатор, сәяси тәрбия, дәреслекләр

Гомуми белем дәрәҗәсе – теләсә кайсы милләтнең һәм җәмгыятьнең мәдәни үсешен билгеләүче төп билгеләрнең берсе. Россиядә XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында белемлелек дәрәҗәсе шактый түбән булу Октябрь революциясеннән соң яшь Совет хөкүмәте алдына иң беренче һәм әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе итеп халыкның грамоталылык дәрәҗәсен күтәрү бурычын куюга сәбәп була. Ләкин бу өлкәдә үзгәрешләрне бары тик революция казанышы буларак кына карау дөрес булмас. Бигрәк тә татар халкына мөнәсәбәттә. Чөнки татарлар арасында гыйлемлелекнең бик борынгы заманнарда ук шактый киң таралуы мәгълүм. XIX гасырда иҗтимагый тормышта, бигрәк тә мәгариф өлкәсендә, башланган үзгәрешләр – мәгърифәтчелек, җәдитчелек хәрәкәтләренең дә асылында милләтне мәгърифәтле, мәдәниятле итү идеясе ята. Революциягә кадәр үк дөнья күргән күп кенә чыганакларда, шул исәптән рус һәм Европа галимнәренең хезмәтләрендә, татарларның белемлелек дәрәҗәсе буенча Россия халыклары арасында иң югары урыннарны биләве турындагы фикерләр әйтелеп килде. Тик совет чорында моның киресе расланып киленде.

П. Знаменский билгеләп үткәнчә, «татар кешесе рус грамотасын да бик җиңел үзләштерә ала, татар солдатлары русларга караганда укырга-язарга тизрәк өйрәнәләр» [6, 24 б.]. Татарларның революциягә кадәр белем дәрәҗәсе югары булу турындагы фикерләр атаклы рус галиме Я.Коблов хезмәтләрендә дә искә алына. Ул: «Россиянең Көнчыгыш өлешендә яшәүче халыклар арасында мөселман татарлар укый-яза белү буенча беренче урында торалар. Аларда грамоталылык дәрәҗәсе хәтта руслар белән чагыштырганда да югарырак» [8, 1 б.]; «Россиядә Казан татарлары кебек укый-яза белү киң таралган башка халыкны атау кыен. Укый-яза белмәгән татар кешесен бик сирәк очратырга мөмкин», – дип яза [7, 4 б.]. А. Сперанский да татарлар арасында грамоталылыкның русларга караганда киңрәк җәелүен раслый, әмма аның дини характерда булуын ассызыклый [17, 9 б.]. Шулай итеп, әлеге рус чыганакларыннан чыгып кына да Октябрь революциясенә кадәр татарлар арасында гарәп хәрефләре нигезендә укый-яза белү дәрәҗәсе киң җәелгән булуы, тик халык санын алу һәм һәртөрле ревизияләрдә бары тик русча укый-яза белү генә исәпкә алыну сәбәпле, татарларның белемлелек дәрәҗәсе турында ялгыш картина тудырылуы күренә. Моннан тыш, татарларның һәртөрле «ревизия»ләр вакытында үзләрен укый-яза белмәүче итеп күрсәтүләре дә билгеле: «ачы тарихи тәҗрибәгә ия булган татарлар рус администрациясе тарафыннан үткәрелгән исәп, сан алулардан мөмкин кадәр качалар, аларда дини-милли үзенчәлекләрен чикләү, юк итү, руслаштыру һәм христианлаштыру куркынычын күрәләр» [1, 46 б.]. Шулай итеп, ана телендә, гарәп хәрефләре белән укый-яза белгән кеше белемсез (неграмотный) дип саналган; кайбер аерым очракларда күпмедер дәрәҗәдә рус хәрефләрен белгән кеше дә, алда искә алган сәбәпләр аркасында үзен белемсез дип белдерүне кирәк тапкан. 1897 елгы халык санын алу нәтиҗәләрендә татарлар арасында укый-яза белүчеләр санының түбән булуы да (18,8 %), беренче чиратта, шуның белән билгеләнә. Шул сәбәпле ясалган нәтиҗәләр гомуми күрсәткечләр белән (аерым алганда руслар арасында укый-яза белү) чагыштырганда күпкә түбән булып күренгән. Бу хәл 1926 елгы халык санын алу кампаниясенә кадәр дәвам итә. 20 нче еллар башында һәрбер халыкның үз телендә белем алуга хокукы турындагы мәсьәлә каралып, уңай хәл ителгәннән соң гына [19, 51–60 б.] татарларның гарәп шрифтында укый-яза белүләре грамоталылык дәрәҗәсе итеп таныла башлый [13, 16 б.]. 1926 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча татарлар арасында грамоталылык дәрәҗәсе 92,5% булып, алар СССР халыклары арасында беренче урынга чыгалар [4, 60 б.].

Шулай итеп, татарлар арасында ликбез үткәрүнең, башка милләтләр белән чагыштырганда, шактый үзенчәлекләре бар. Татар язуының берничә тапкыр үзгәреш кичерүен, ягъни графика алыштыруларны да исәпкә алсак, рәсми хисапларда грамоталылык дәрәҗәсе ни өчен югары булмаганлыгы ачык аңлашыла. 1927 елда гарәп графикасына нигезләнгән татар язуының яңалиф (латин алфавитына нигезләнгән язу) белән алыштырылуы гарәп

хәрефләрен белгәннәрнең кабат белемсез дип танылуына китерә, белемсезләр саны тулылана, 92,5 % ның күпмедер өлеше кабат грамотасыз дип табыла. 1939 елда рус графикасына нигезләнгән яңа алфавитка күчкәндә дә бу күренеш беркадәр күзәтелә, ләкин ликбез мәктәпләрендә рус теленә өйрәтү дә каралу сәбәпле, ул кадәр үк киң таралмый. Болар барысы да – Россиядә рус булмаган милләтләргә карата алып барылган мәгариф сәясәтенең нәтиҗәләре. Грамоталылык дәрәҗәсен ана телен белү (туган тел компетенцияләре) нигезендә билгеләгән дөнья тәҗрибәсенә килсәк, татарларның Октябрь революциясенә кадәр укый-яза белү дәрәҗәсенең югары булуын тану дөнья стандартларына туры килә. Татар мәгарифе мәсьәләләрен җентекле өйрәнгән тарихчы-галимнәр аны 80 % тирәсе дип билгелиләр [1, 46–47 б.]. Совет чорында дөнья күргән хезмәтләрдә бу проблема бары тик партия һәм совет идеологиясе күзлегеннән чыгып кына каралды, шул сәбәпле тулы һәм дөрес мәгълүматлар алу мөмкинлеге тудырылмады.

Гомумән алганда, Россиядә мәктәп системасыннан тыш эшләүче «зурлар мәгарифе» (образование взрослых) дигән төшенчә һәм аның тормышка ашырылуы революциягә кадәр үк була (якшәмбе мәктәпләре һ.б.). Татарлар арасында зурларны укыту эше РСФСР Халык мәгарифе комиссарлары советының 1919 елның 26 декабрендә дөнья күргән 8 яшьтән алып 55 яшькәчә халыкны күздә тоткан «РСФСР халыклары арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү турындагы» Декреты кабул ителгәннән соң киң җәелдерелә. I Бөтенроссия мәктәптән тыш белем бирү буенча үткәрелгән съездда «Укый-яза белмәүчелекне бетерү турында» резолюция кабул ителә, яшүсмерләр һәм зурлар өчен мәктәп типлары билгеләнә. 1919 елның июнендә Казан шәһәрендә уздырылган мәктәптән тыш белем бирү буенча I Казан губерна съездында зурлар мәктәпләре оештыруны кичектермичә башлау турында сүз алып барыла [18, 6 б.]. 1920 елның 21 гыйнварында Казан губерна башкарма комитеты президиумы «Казанда һәм губернада укый-яза белмәүчелекне бетерү проекты»н кабул итә. Шушы ук елның 25–29 мартында узган мәктәптән тыш белем бирү буенча III губерна съездында башланып киткән кампанияне үткәрү буенча конкрет план билгеләнә. Озакламый Казан губернасы буенча ликпунктларның саны 5717 гә җитә [4, 58 б.]. 1920 елның 30 ноябрендә ТАССР халык мәгарифе комиссариаты каршында ликбез буенча бөтентатар комиссиясе төзү турындагы күрсәтмә кабул ителә [13, 23 б.]. Әлеге комиссиянең төп бурычларыннан берсе – ликбез мәктәпләре өчен дәреслек-кулланмалар, әлифбалар төзүне оештыру була. Эшнең нәтиҗәсе буларак, 1920 елның җәендә үк Казан губернасында 50 мең әлифба дөнья күрә [11, 88 б.]. Иң беренче әлифбаларның авторлары М.Корбангалиев һәм Т.Бәдигый була [9; 2]. 1921 елда М.Корбангалиевнең «Олыларны укырга өйрәтү юллары һәм дәрес бирү үрнәкләре» дигән методик кулланмасы басылып чыга. Республикада яшәүче башка рус булмаган халыклар белән чагыштырганда, методик әдәбият белән тәэмин ителеш ягыннан татарлар беренче урында була һәм

бу тенденция кампания азагына кадәр саклана. Бу вакытта Казан шәһәрендә аерым татар инструкторы да (ликвидаторларга, ягъни ликбез мәктәпләрендә укытучыларга методик яктан ярдәм күрсәтүче махсус әзерлекле педагог) була. Махсус матбугат органы ачу турындагы мәсьәлә күтәрелсә дә, ул бары тик 30 нчы елларда гына хәл ителә: аз белемлеләр өчен «Башлап уку», «Уку ударнигы» газеталары басыла башлый.

Ликбез системасында «грамоталы» сүзе, гомуми мәгънәдән аермалы буларак, бигрәк тә беренче чорда, рус хәрефләрен тану, иң элементар рәвештә русча укый-яза белүне аңлаткан. Баштарак уку-язуга һәм санарга өйрәтү максат итеп алынса, 30нчы елларда, моннан тыш, икътисади география, җәмгыять белеме, тарих, авыл хуҗалыгы һәм зоотехник (авылда) һәм политехник (шәһәрдә) белем бирелгән. Ликбез мәктәпләрендә укыту, куелган максаттан чыгып, ике баскычка (төргә) бүленгән: белемсезләр һәм аз белемлеләрне укыту; шуңа карап белем бирүнең эчтәлеге билгеләнгән. Әмма ул үзгәреп торган: 20 нче елларда хәреф танырга өйрәнгән, саный белгән кеше аз белемле саналса, 30 нчы елларда инде ликпунктларны тәмамлаучылардан газеталар белән эш итә белү, беркадәр сәяси мәсьәләләрдә ориентлаша белү таләп ителгән.

Ликбез кампаниясенең беренче чоры билгеле бер эзлеклелекнең булмавы һәм алып барылган эшләрнең төрлелеге белән характерлана. Агитация һәм пропаганда нигездә рус телендә алып барылса да, гади халык өчен белемле булуның әһәмиятен аңлаткан чаралар – әңгәмәләр, сәяси митинглар, җыелышлар, конференцияләр, спектакльләрне төрле милләт телләрендә үткәрү дә күзәтелә. Мәсәлән, Буа кантонында 1920 елның гыйнварында рус, чуваш, татар телләрендә 30 спектакль куела, аларда мәктәпләргә чакыру, наданлыкның кеше тормышы өчен зыянлы булуы турындагы фикерләр яңгыраш ала [13, 20–21 б.].

Беренче чорда зурлар өчен татар телендә язылган уңышлы дәреслекләр һәм татарча эшләүче ликвидаторларның аз булуы эшкә комачаулык ясый. Уңышлы яклардан ликбез мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү эшенең яхшы куелышын атарга мөмкин. 1921 елгы ачлык нәтиҗәсендә укыту эшләре сүлпәнәя, ликпунктлар саны кими, губернада 1922 елга аларның саны 215 кенә кала [18, 13 б.]. Балалар мәктәпләренең аз булуы да кампаниянең үтәлешенә комачаучылык итә. 1922 елда 15 татар ликпункты ачыла. 1923/24 уку елыннан укый-яза белмәүчелекне бетерү кампаниясе планлы, эзлекле рәвештә, 1920 елгы халык санын алу нәтиҗәләренә нигезләнеп төзелгән бердәм план нигезендә тормышка ашырыла башлый. Беренче чорда төп игътибар 18–35 яшьлекләрне укытуга бирелә. Татарстанда 1924 елда зурларны укыту өчен 963 мәктәп ачыла, 9 мең кеше әлеге мәктәпләрне бетерә [14]. Бу елда кантоннарда ачылган ликбез мәктәпләренең гомуми саны 542 булса, шуларның 272 се – татар мәктәбе була [15]. Зурлар мәктәпләрен тагын да күбәйтү, һәр волость саен 10 мәктәп ачу, уку кирәк-яраклары белән мөмкин кадәр күбрәк тәэмин итү мәсьәләсе күтәрелә [14]. Киң халык массаларын җәлеп итү максатыннан «Бетсен наданлык» җәмгыяте төзелә, урын-

нарда аның күпсанлы бүлекчәләре (ячейкалары) барлыкка килә. Белемсезлек белән көрәшкә халык үзе – яңа гына ликпунктларны тәмамлаган эшче һәм крестьяннар җәлеп ителә («Наданлык фронтында бөтенебез күмәкләшеп көрәшәбез, өмә булы эшлибез» [14]). Яңа төр чаралар – «атналыклар», «өчкөнлекләр» уздыру да эшне югары баскычка күтәрергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, шундый атналыкларның берсе 1924 елның 25 октябре – 1 ноябрендә уза [14]. Уку-укыту әсбаплары белән тәэмин ителеш мәсьәләсе дә уңай якка кузгала: Казан шәһәрендә «Бетсен наданлык» җәмгыятенең Татар өлкә советы типографиясе оештырыла. Ликбез мәктәпләрендә белем бирү методикасын камилләштерү максатында Казанда 1923 елның 15–20 сентябрендә I Көнчыгыш методик конференциясе уздырыла. Анда зурларны укыту өчен бөтен сүзләр методының уңышлылыгы раслана һәм төп метод буларак кабул ителә.

Махсус орган булдырылганчы, ликбез кампаниясенең эшен яктыртуда көндәлек вакытлы матбугат, аерым алганда, «Крестьян гәзите», «Кызыл Татарстан» кебек татар газеталарының роле зур була. Аларда республикада эшнең барышы, уңышлы яклар, кимчелекләр турындагы мәкаләләр басыла, эш тәҗрибәсе яктыртыла, уку-язуга өйрәнүнең, белем алуның әһәмияте ассызыклана, агитация һәм пропаганда алып барыла. Мәсәлән, «Крестьян гәзите»нең 1924 елгы 12 сентябрь санында басылып чыккан «Укый-яза белмәүчелек белән көрәш» дигән мәкаләдә (авторы Х.Вәлиуллин) авыл халкының әлеге кампанияне яклавы, «Бетсен наданлык» җәмгыяте файдасына 11 пот 16 кадак арыш җыелуы турында хәбәр ителә. Ярдәм итүнең бу формасын бер ай дәвамында алып баруны планлаштырганлыкны истә тотканда [3], аның шактый масштаблы күренеш булганлыгын чамалау кыен түгел.

Татарстанда ликбез мәктәпләренең берничә төрен аерып күрсәтергә мөмкин. Иң беренче булып ликпунктлар барлыкка килә. Алар укырга-язарга өйрәтүне максат итә, уку вакыты 3–4 ай. Ликпункт тәмамлаучыларның үзлекләреннән шөгыльләнүләрен дәвам итмәгән очракта, уку-язу күнекмәләрен онытулары (рецидив) күзәтелә. Шул сәбәпле, ликпунктларны тәмамлаучылар өчен аз белемлеләр мәктәпләре оештырыла башлый. Шулай ук сезонлы ликпунктлар ачу тәҗрибәсе дә (алар җәй айларында эшләгән), индивидуаль-төркемле укыту, аз белемлеләр түгәрәкләре кебек формалар да кулланылган. Ликпунктлар (аларны грамота мәктәпләре дип тә йөрткәннәр) балалар мәктәпләре, берләшмәләр каршында, клубларда, китапханәләрдә, уку йортларында, эшчеләр тулай торакларында оештырылганнар. Шулай ук белем алучыларның социаль һәм һөнәри составыннан чыгып та бүленеш булган: эшчеләр, крестьяннар, хезмәтчеләр, хуҗабикәләр, профсоюз әгъзалары өчен һ.б. Дәреслекләр, аерым алганда, әлифбалар төзегәндә дә бу принцип нигез итеп алынган (авыл өчен крестьян әлифбасы һәм шәһәр варианты (эшчеләр өчен) [10; 12; 16]. Шул елларда хатын-кызлар өчен аерым мәктәпләр ачу мәсьәләсе күтәрелә, озакламый андый мәктәпләр урыннарда ачыла.

20 нче елларның икенче яртысында гомумән мәгариф өлкәсендә барган үзгәрешләр ликбез мәктәпләрендә дә чагылыш таба – дәүләт телләрен укытуга игътибар арта. Шул уңайдан татар ликпунктлары өчен рус теле дәреслекләре язу эше күтәрелә. Гомумән алганда, 20 нче еллар азагына татар ликпунктларында укыту методикасы тулысынча эшләнеп беткән була инде.

Ликбез мәктәпләренең төп максаты олыларны укырга-язарга һәм санарга гына өйрәтү булмыйча, иң беренче чиратта совет иленең гражданнарында яңа, пролетар аң, социалистик җәмгыять төзелешендә катнашу теләге тәрбияләүдән гыйбарәт була. Азаккы максат – белемле һәм сәяси яктан грамоталы кеше формалаштыру. Шул максатларны тормышка ашыру сәяси сәгатьләр уздыру, мәктәптән тыш пропаганда алып бару, белем алучыларны сәяси тормышка тарту юллары аша алып барылган. Шуңа күрә укырга-язарга өйрәткәндә дә җәмгыяви-сәяси тормыш материалына нигезләнелгән.

Укыту алымнарын сайлауга килгәндә, беренче чорда, беркадәр өстәмә материаллар кертеп, балалар мәктәпләре тәҗрибәсенә таяныла. Әмма иске метод һәм алымнардан азат булган яңа методикага нигезләнеп укыту тарафдарларының карашлары дөрес дип табыла һәм нәтиҗәдә укытуның комплекслы методы, бөтен сүзләр, әңгәмә ысуллары, уку эчтәлеген тормыш һәм һөнәри эшчәнлек белән, теорияне практика белән бәйләп алып бару, белем бирүдә эзләнү-тикшерену элементларын куллану, иллюстрация һәм күрсәтмәлелеккә игътибарны юнәлтү кебек метод һәм алымнарга өстенлек бирелә. Психологик аспектны («һәрбер яңа нәрсә балаларны үзенә тарта, ә олылар үзләренә күпмедер таныш булган нәрсәләр белән генә кызыксыналар» [5, 17 б.]) истә тотып эшләнгән методика отышлы дип табыла. Шулай итеп, уку-укыту барышын оештыруның яңа, моңарчы күрелмәгән формалары кертелә («Дальтон-план», «бригада-лаборатор», «проектлар методы» һ. б.).

1927/28 уку елыннан кертелгән индивидуаль һәм индивидуаль-төркемле укыту моңарчы уку мөмкинлеге булмаганнарны тарту өчен бик уңайлы була. Нәтиҗәдә бик күп хатын-кызлар, вак предприятиеләрдә эшләүчеләр, авылда яшәүчеләр ликпунктларга килә. Татарстан шартларында кулланылган үзенчәлекле оештыру формасы буларак зурлар һәм балалар төркемнәреннән гыйбарәт булган ликпунктларны атарга мөмкин. Балалар өчен мәктәпләр ачылмаган авылларда мондый оештыру формасы уңай нәтиҗәләргә китергән. Шулай ук укытуны практика белән бәйләп алып баруга, җитештерү оешмаларына экскурсияләр оештыру, экспериментлар ясауга игътибар бирелә.

Ликбез кампаниясенең беренче елларында грамотасызлар рәте гомуми мәктәпкә тартылмаган 8–12 яшьлек балалар исәбенә тулылана. Бу мәсьәлә бары тик 1930 елда «Гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирү» турындагы карар кабул ителгәннән соң гына уңай чишелә.

Яшь совет иле гражданнары В.И. Ленинның «1927 елның 7 ноябренә чаклы советлар илендә укый-яза белмәгән бер генә кеше дә калмаска тиеш» дигән васыятен үтәргә тырышсалар да [14], ликбез кампаниясен рәсми рәвештә 30 нчы еллар азагына кадәр сузыла. Татар телендә нәшер ителгән уку әсбаплары исә укый-яза белмәүчелекнең күпмедер дәрәҗәдә 50 нче елларга кадәр саклануы турында сөйли.

## ӘДӘБИЯТ


1. Амирханов Р.У. Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. Казань, 1992. С. 22–60.

2. Бәдигый Т. Зурлар әлифбасына үрнәк. Казан: Татар. дәүл. нәшр., 1920. 15 б.

3. Вәлиуллин Х. Укый-яза белмәүчелек белән көрәш // Крестьян гәзите. 1924. 12 сентябрь.

4. Галиев Р. Беренче күчмә мәктәпләр // Совет мәктәбе. 1972. № 10. Б. 58–61.

5. Дистанов Г. Укый-яза белмәүчеләрне һәм аз белемлеләрне укытучылар өчен кулланма. Казан: Татиздат, 1926. 104 б.

6. Знаменский П. Казанские татары. Казань: Типо-лит. Имп. Ун-та, 1910. 67 с.

7. Коблов Я.Д. Конфессиональные школы казанских татар. Казань, 1916. 119 с.

8. Коблов Я. Мечты татар-магометан о национальной общеобразовательной школе. Казань: Типо-лит. Имп. Ун-та, 1908. 20 с.

9. Корбангали М. Олылар өчен рәсемле татар әлифбасы. Казан: Милләт, 1920. 46 б.

10. Корбангалиев М., Бәдигый Х. Крестьян әлифбасы (зурлар өчен). М., 1925. 48 б.

11. Куманев В.А. Социализм и всенародная грамотность. М: Наука, 1967. 327 с.

12. Мөхәммәдев М.Н. Эшчеләр әлифбасы. М., 1924. 80 б.

13. Муртазина Л.Р. Педагогический анализ деятельности ликбезов (на примере Республики Татарстан). Казань: Печатный двор, 2002. 135 с.

14. Парсин М. 25 октябрьдән башлап 1 ноябрьгә чаклы укый-яза белмәүчелекне бетерү атналыгы ясала // Крестьян гәзите. 1924. 24 октябрь.

15. Парсин М. Наданлыкның тамырына балта чабыйк! // Крестьян гәзите. 1924. 19 декабрь.

16. Саттаров Ш. Кызылармеец әлифбасы. М.: Дәүл. Хәрби нәшр., 1925. 64 б.

17. Сперанский А. Казанские татары (Историко-этнографический очерк). Казань: Центр. тип., 1914. 30 с.

18. Хакимова Р.Ш. Борьба татарской партийной организаци за ликвидацию неграмотности среди населения // Борьба КПСС за развитие народного образования и культуры. Казань, 1972. С. 3–30.

19. Языковая политика в Республике Татарстан. Казань, 1998. С. 51–60.

*Мортазина Л.Р.* Совет властеның беренче елларында татарлар арасында укый-яза белмәүчелекне бетерүнең кайбер мәсьәләләре (ТАССР мисалында)

**Автор турында белешмә:** Мортазина Ләлә Рәис кызы – педагогика фәннәре кандидаты, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7, Казан, Российская Федерация); lyalyamur@mail.ru

## НЕКОТОРЫЕ ВОПРОСЫ ЛИКВИДАЦИИ БЕЗГРАМОТНОСТИ СРЕДИ ТАТАР В ПЕРВЫЕ ГОДЫ СОВЕТСКОЙ ВЛАСТИ (НА ПРИМЕРЕ ТАССР)

***Л.Р. Муртазина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*lyalyamur@mail.ru*

В статье раскрываются некоторые особенности проведения ликвидации безграмотности – одной из масштабных кампаний, проведенных молодым советским государством в первые годы его существования. Указываются формы и пути ее реализации в условиях Татарской республики, уделяется внимание также учебникам, методическим пособиям для татарских ликпунктов, освещению проблемы на страницах татарских газет.

**Ключевые слова:** ликбез, безграмотность, обучение грамоте, ликпункт, ликвидатор, политическое воспитание, учебники

**Сведения об авторе:** Муртазина Ляля Раисовна – кандидат педагогических наук, ведущий научный сотрудник, Центр истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ (420111, ул. Батурина, 7, Казань, Российская Федерация); lyalyamur@mail.ru

## SOME QUESTIONS OF ELIMINATION OF ILLITERACY AMONG TATARS IN THE FIRST YEARS OF THE SOVIET POWER (THE CASE OF TASSR)

***L.R. Murtazina***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*lyalyamur@mail.ru*

The article considers some aspects of conducting elimination of illiteracy – one of large-scale campaigns held by the young Soviet state in the first years in power. Forms and ways of its implementation in the conditions of the Tatar Autonomous Soviet Socialist Republic (TASSR) are specified. The article also focuses on the textbooks and

methodical manuals for Tatar schools and on illumination of the issue on the pages of Tatar newspapers.

**Keywords:** elimination of illiteracy, illiteracy, literacy training, political education, textbooks

REFERENCES

1. Amirhanov R.U. Nekotorye osobennosti razvitija narodnogo obrazovanija u tatar v dooktjabr'skij period [Some Features of Development of Tatars' National Education during the before-October Period ]. *Narodnoe prosveshhenie u tatar v dooktjabr'skij period* [National Education of Tatars during the before-October Period] Kazan, 1992, pp. 22–60. (in Russian)

2. Bädigyj T. *Zurlar älifbasyna ürnäk* [An Example of an ABC-Book for Adults]. Kazan, Tatar State Publishing House, 1920. 15 p. (in Tatar)

3. Väliullin H. Ukyj-jaza belmäüchelek belän köräsh [Fight Against Illiteracy]. *Krest'jan gäzite – Peasant Newspaper.* 1924. September 12. (in Tatar)

4. Galiev R. Berenche küchmä mäktäplär [First Mobile Schools]. *Sovet mäktäbe – Soviet School*, 1972, no. 10, pp. 58–61 (in Tatar)

5. Distanov G. *Ukyj-jaza belmäüchelärne häm az belemlelärne ukytuchylar öchen kullanma* [Grant for Training the Illiterate and the Semiliterate]. Kazan, Tatizdat Publ, 1926. 104 p. (in Tatar)

6. Znamenskij P. *Kazanskie tatary* [The Kazan Tatars]. Kazan, Typo-lithography of the Imperial University, 1910. 67 p. (in Russian)

7. Koblov Ja.D. *Konfessional'nye shkoly kazanskih tatar* [The Confessional Schools of the Kazan Tatars]. Kazan, 1916. 119 p. (in Russian)

8. Koblov Ja. *Mechty tatar-magometan o nacional'noj obshheobrazovatel'noj shkole* [Dreams of Tatars Mohammedans about the National Secondary School]. Kazan, Typo-lithography of the Imperial University, 1908. 20 p. (in Russian)

9. Korbangali M. *Olylar öchen räsemle tatar älifbasy* [Tatar ABC-Book for Adults with Drawings]. Kazan, Millät Publ, 1920. 46 p. (in Tatar)

10. Korbangaliev M., Bädigyj H. *Krest'jan älifbasy (zurlar öchen)* [Rural ABC-Book for Adults]. Moscow, 1925. 48 p. (in Tatar)

11. Kumanev V.A. *Socializm i vsenarodnaja gramotnost'* [Socialism and Nationwide Literacy]. Moscow, Nauka Publ, 1967. 327 p. (in Russian)

12. Möhämmädev M.N. *Eshchelär älifbasy* [ABC-Book for Workers]. Moscow, 1924. 80 p. (in Tatar)

13. Murtazina L.R. *Pedagogicheskij analiz dejatel'nosti likbezov (na primere Respubliki Tatarstan)* [Teacher Analysis of the Likbez Campaign (Through the Example of the Republic of Tatarstan)]. Kazan, Pechatnyj Dvor Publ, 2002. 135 p. (in Russian)

14. Parsin M. 25 oktjabr'dän bashlap 1 nojabr'gä chakly ukyj-jaza belmäüchelekne beterü atnalygy jasala [October 25 – November 1 Elimination of Illiteracy Week is organized]. *Krest'jan gäzite – Peasant Newspaper.* 1924. October 24. (in Tatar)

15. Parsin M. Nadanlyknyñ tamyryna balta chabyjk! [Let's Do Away with Illiteracy!]. *Krest'jan gäzite – Peasant Newspaper.* 1924. December 19. (in Tatar)

16. Sattarov Sh. *Kyzylarmeec älifbasy* [ABC-book of a Red Army Soldier]. Moscow, Däül. Härbi Publ., 1925. 64 p. (in Tatar)

17. Speranskij A. *Kazanskie tatary (Istoriko-jetnograficheskij ocherk)* [The Kazan Tatars (A Historical and Ethnographic Sketch)]. Kazan, Central Printing House, 1914. 30 p. (in Russian)

18. Hakimova R.Sh. Bor'ba tatarskoj partijnoj organizaci za likvidaciju negramotnosti sredi naselenija [Fight of the Tatar Party Organization for Elimination of Illiteracy among the Population]. *Bor'ba KPSS za razvitie narodnogo obrazovanija i kul'tury* [Fight of the CPSU for Development of the National Education and Culture]. Kazan, 1972, pp. 3–30. (in Russian)

19. *Jazykovaja politika v Respublike Tatarstan* [Language Policy in the Republic of Tatarstan]. Kazan, 1998, pp. 51–60. (in Russian)

**About the author:** Lyalya R. Murtazina is a Candidate of Science (Pedagogy), Leading Research Fellow, the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); lyalyamur@mail.ru